ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.04.2020 г. Заинск № 179

**“Чернобыль атом электр станциясендәге һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны дәүләт торак сертификаты алуга исәпкә кую һәм дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында”**

"Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Торак кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. Чернобыль атом электр станциясендәге һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны дәүләт торак сертификаты алуга исәпкә кую һәм дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. “Чернобыль атом электр станциясендәге һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны дәүләт торак

сертификаты алуга исәпкә кую һәм дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында”, 2018 елның 07 декабрендәге 1806 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән, Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июлендәге 1189 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары М.И. Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**

Юрист

С.А.Филюшина
7 07 75

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
22.04. 2020 ел
179 номерлы карарына
кушымта.

**Чернобыль атом электр станциясендәге һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны дәүләт торак сертификаты алуга исәпкә кую һәм дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - регламент) Чернобыль атом электр станциясендәге һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны дәүләт торак сертификаты алуга исәпкә кую һәм дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәтне алучылар: физик затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитет урнашкан урын: Зәй шәһәре, Крупская ур., 6 йорт.

Бүлекнең урнашкан урыны: Зәй шәһәре, Крупская ур., 6 йорт.

Эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8.00 - 17.00;

Кабул итү көннәре:

сишәмбе - 8.00 - 17.00;

пәнҗешәмбе - 8.00 - 17.00;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Төшке ял – 12.00 - 13.00.

Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмәләр өчен телефон: 7 07 75.

Керү - шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайты (алга таба - “Интернет” челтәре): (http:/ www.zainsk.tatar.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат түбәндәгеләрдән алынырга мөмкин:

1) Башкарма комитет биналарында урнашкан мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматлы мәгълүмат стендлары ярдәмендә, стендларда урнаштырыла торган мәгълүмат

шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларында) муниципаль хезмәт турында белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша муниципаль районның рәсми сайтыннан (http:/ www.zainsk.tatar.ru);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/);

4) Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http:/ www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта (бүлектә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә - шәхсән яисә телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә - кәгазьдә почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бүлек белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм Башкарма комитет биналарындагы мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ ТК) (РФ законнары җыентыгы, 03.01.2005, №1 (1 өлеш), 14 ст.);

«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба - 1244-1 номерлы Федераль закон) (Ведомости СНД и ВС РСФСР, 1991, № 21, ст. 699);

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм «Теча» елгасына радиоактив калдыклар ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 175-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 30.11.1998, № 48, 5850 ст.);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2007 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 06.10.2003, №40, 3822 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 ст.);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 59-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Чернобыль АЭС һәлакәте нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында" РСФСР Законының гамәлдә булуын аеруча хәвефле бүлекчәләр гражданнарына тарату хакында” 1991 елның 27 декабрендәге 2123-1 номерлы Россия Федерациясе Югары Советы карары (2123-1 номерлы карар);

«2011-2015 елларга торак федераль максатчан программасы турында» 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба –1050 номерлы карар) (РФ законнары җыентыгы, 31.01.2011, №5, 739 ст.);

"Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү" Россия Федерациясе дәүләт программасының "Торак белән тәэмин итү һәм торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүдә дәүләт ярдәме күрсәтү" ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында Дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләре (алга таба - Дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләре) (2006 елның 21 мартындагы 153 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган) (2019 елның 15 ноябрендәге редакциясе);

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004 ел);

Зәй муниципаль районы Советының 2014 елның 24 июнендәге 385 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы (алга таба - Устав);

Зәй муниципаль районы Советының 2016 елның 17 мартындагы 82 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба - БК турында нигезләмә);

Башкарма комитет җитәкчесенең 2007 елның 29 мартындагы 113 номерлы боерыгы белән расланган бүлек турында нигезләмә (алга таба - бүлек турында нигезләмә);

Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2016 елның 24 мартындагы 83 номерлы күрсәтмәсе белән расланган эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба - кагыйдәләр).

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт торак сертификаты - гражданның торак урыны сатып алу өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән социаль түләү (торак субсидиясе, субсидия) алуга хокукын раслаучы исемле таныклык.

Сертификат кыйммәтле кәгазь булып тормый.

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтәге эш урыны - муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул итеп алу һәм бирү, консультацияләр бирү тәрәзәсе;

техник хата - муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән хата һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, шуларга нигезләнеп кертелгән документлардагы белешмәләрнең туры килмәвенә китергән хата (описка, опечатка, грамматик яки арифметик хата яки шуларга охшаш хаталар).

Әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтүне сорату аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсе 2 пункты). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 кушымта).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең атамасы | Чернобыль АЭС һәлакәте, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга һәм аларга тиңләштерелгән затларга дәүләт торак сертификаты алуга исәпкә кую һәм аны бирү | РФ ТК;<br>1244-I номерлы Федераль закон (15.05.91) |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеру органы исеме | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты | БК турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм, ул кергәндә, Дәүләт торак сертификатын бирү;<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | 1050 номерлы карар |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итүнең зарурлыгын исәпкә алып, әгәр туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган булса, шул очракта муниципаль хезмәт | Планлаштырылган елда субсидия алырга теләк белдергән гражданнар исемлеген төзү һәм документлар әзерләү, гражданнарның категорияләре буенча бүлеп, аны ТР Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгына тапшыру - гаризаны кирәкле документлар белән теркәп биргән вакыттан 17 эш көне эчендә.<br>Мөрәҗәгать итүчегә сертификатның керүе турында хәбәр итү ике көннән дә артык түгел. | РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 21 мартындагы 153 номерлы карары;<br>Дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 24 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүне туктату срогы | Чират җитүне көтү вакыты муниципаль хезмәт күрсәтү чорына керми. | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелергә тиешле хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысулларының, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибенең тулы исемлеге | 1) Гариза (1 кушымта);<br>2) гражданның торак урыны белән федераль бюджет акчалары исәбеннән тәэмин ителү хокукын раслый торган документ<br>3) торак шартларын яхшыртуга (торак биналарга) мохтаҗ буларак исәпкә кую турында торакны исәпкә алу һәм бүлү органы карарыннан өземтә;<br>4) торак урынның өстәмә мәйданына хокукны раслый торган документның күчермәсе (мондый хокук Россия Федерациясе законнары белән бирелгән очракларда);<br>5) гаиләнең һәр әгъзасының шәхесен таныклый торган документларның күчермәләре;<br>6) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш йөртсә);<br>Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга яисә төп нөсхәне күрсәтеп тапшырылырга тиеш. Гражданнар ведомство максатчан программасында катнашу турында гариза биргән җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә миграция өлкәсен контрольдә тоту органында соратып алалар:<br>ведомство максатчан программасында катнашу турында гариза биргән граждан белән бергә торак урынында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләрдән торган документ (ведомство максатчан программасында катнашу турында гариза биргән граждан мөстәкыйль рәвештә тәкъдим итәргә хокуклы);<br>Җирле үзидарә органнары карамагында булган очракта, ведомство максатчан программасында катнашу турында гариза биргән гражданның 2,3 пунктларда күрсәтелгән документлары (җирле үзидарә органы тарафыннан соратып | РФ ТК;<br>Дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 16, 19 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | алынмый) тапшырылмый.<br>Планлаштырыла торган елда ведомство максатчан программасында катнашуын раслаган гражданнар исемлегенә кертү өчен граждан-ведомство максатчан программасында катнашучы планлаштырганнан алдагы елның 1 гыйнварыннан 1 июленә кадәр чорда аның исәп эше булган җирле үзидарә органына, планлаштырыла торган елда ведомство максатчан программасында катнашу турында гариза тапшыра (ирекле рәвештә).<br>2нче кушымта нигезендә торак сертификаты алуга гариза (рапорт);<br>Дәүләт яисә муниципаль торак фондларында урнашкан торак бинада социаль наем шартнамәсе нигезендә торак бинада яшәүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары күрсәтелгән шартнамәне өзү турында һәм биләгән торак урынны яисә аның һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының милек хокукыннан азат итү турында һәм милеккә карата хокукларның чикле булуыннан азат итеп, әлеге торак бинаны дәүләт яисә муниципаль милеккә түләүсез читләштерү турында йөкләмә кабул итә (3нче кушымта нигезендә); | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, шулай ук дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле документларның | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүмат булган) (гаиләнең һәр әгъзасына);<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле | |

| | | |
|---|---|---|
| тулы исемлеге, шулай ук аларны мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан, шул исәптән электрон рәвештә, алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; дәүләт органы, җирле үзидарә органы йә шушы документлар белән эш итүче оешма | үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә һәм ул муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1) документларны тиешле затның тапшырмавы;<br>2) тапшырылган документларның әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) гаризада һәм гаризага теркәлә торган документларда төзәтүләр, аларның эчтәлеген төрлечә аңларга мөмкинлек бирә торган җитди хаталар булу;<br>4) документларны тиешле булмаган органга | |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшыру; | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>а) дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 5 пунктының тиешле пунктчасында күрсәтелгән таләпләргә гражданның туры килмәве;<br>б) әлеге регламентның 2,5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яисә тулысынча тапшырмау;<br>в) тәкъдим ителгән документлардагы белешмәләрнең дөрес булмавы;<br>г) торак шартларын яхшыртуга яисә федераль бюджет акчалары исәбеннән бирелгән социаль түләүдән яисә субсидиядән файдаланып торак урыны белән тәэмин итүгә хокукны алдан гамәлгә ашыру;<br>д) торак шартларын начарайтуга китергән гамәлләр кылган көннән соң (биш ел) срок тәмамланмаган;<br>е) субсидияне федераль бюджет акчалары исәбеннән файдаланып, торак шартларын яхшыртуга элегрәк хокукны гамәлгә ашыру. | Дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 22 пункты;<br>РФ ТК 53 ст.;<br>РФ ТК 54 ст. |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт | Чират булганда муниципаль хезмәт алуга гариза | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | бирү 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмый. | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза килгәннән соң бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән сорау ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтеп тору һәм кабул итү урынына, шул исәптән күрсәтелгән объектлардан инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр. | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз килү тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күченеп йөрү).<br>Муниципаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләргә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып. | |
| 2.15.Муниципаль хезмәт | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтәге эш урыннарында муниципаль хезмәт күрсәтү мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати коммуникация технологияләреннән файдаланып | мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеүә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Инвалидларга бүтәннәр белән бер үк дәрәҗәдә хезмәтләр алырга комачаулаучы киртәләрне җиңәргә ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның | |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм мөрәҗәгать итүченең бер мәртәбә үзара элемтәсе фаразлана. Үзара элемтәнең дәвамлылыгы регламент белән тәгаенләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә консультация, документлар кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://uslugi.tatar.ru сайтыннан, бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, КФҮ сайтыннан алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтләрне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Әгәр закон нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон формада бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы аша (http:/ www.gosuslugi.ru/ бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү;

4) комиссия тарафыннан торак шартларын тикшерү;

5) муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен әзерләү;

6) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче бүлеккә шәхсән, телефон буенча һәм (яки) электрон почта аша муниципаль хезмәт турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен тапшырыла торган документлар формасы һәм башка мәсьәләләр буенча да, кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм рөхсәт алу мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче планлаштырылганга кадәрге елның 1 гыйнварыннан 1 июленә кадәрге чорда шәхсән үзе гариза бирә, аның исәпкә алу эше урнашкан Россия Федерациясе субъектының гражданнарны исәпкә алуны гамәлгә ашыручы башкарма хакимият органы җирле үзидарә органына планлаштырыла торган елда сертификат бирү турында гариза тапшыра һәм документларны шушы регламентның 2.5 пункты нигезендә бүлеккә тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон формада гариза бүлеккә электрон почта аша яки Интернет-кабул итү бүлмәсенә җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Гаризаларны кабул итү белән шөгыльләнүче бүлек белгече башкара:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләүне;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч кәгазе буенча эш иткән очракта);

әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерүне;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерүне (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерүне, төзәтүләр, ассызыклаулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр, аларның эчтәлеген төгәл генә аңларга мөмкинлек бирми торган җитди бозулар булмауны).

Бернинди дә күрсәтмәләр булмаган очракта, бүлек белгече башкара:

гаризаны кабул итү һәм махсус журналда теркәүне;

мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларның күчермәләрен, керүче номерга бирелгән документларны кабул итү датасы, муниципаль хезмәт күрсәтүнең датасы һәм вакыты турында имза куйдырып тапшыруны;

гаризаны Башкарма комитет җитәкчесенә карау өчен җибәрүне.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган очракта, документларны кабул итүне алып баручы бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

гариза һәм документлар 15 минут дәвамында кабул ителә;

гариза кергәннән соң бер көн эчендә теркәлә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гаризаның Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрелүе яисә документларның мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылуы.

3.3.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм гаризаны бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Специалист Отдела направляет в электронной форме посредством системы межведомственного электронного взаимодействия запрос о предоставлении: Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә түбәндәгеләрне бирү турында гаризаны җибәрә:

1) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүмат булган) (гаиләнең һәр әгъзасына);

2) Финанс-шәхси счет.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән гариза нигезендә соратып алына торган документларны (мәгълүматны) тапшыра яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәрне җибәрә (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, ведомствоара соратуга җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса, документ һәм мәгълүмат бирүче органга яисә оешмага ведомствоара гариза кергәннән соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (белешмәләр) яисә бүлеккә җибәрелгән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Торак шартларын комиссия тарафыннан тикшерү

3.5.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

тапшырылган документлардагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерү;

гаиләнең исәпкә алу эшен рәсмиләштерү (барлык документларны аерым папкага туплау);

әлеге регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерү. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, бүлек белгече муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында бәяләмә әзерли. Бәяләмә гаиләнең хисап эшенә тыгып куела.

гаиләнең исәпкә алу эшен иҗтимагый торак комиссиясе каравына җибәрү (алга таба - комиссия).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең комиссия каравына җибәрелгән формалаштырылган исәпкә алу эше.

3.5.2. . Комиссия секретаре гамәлгә ашыра:

кергән документларны өйрәнү;

комиссия утырышы көнен билгеләү;

комиссия әгъзаларына комиссия утырышы көне турында хәбәр итү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: утырыш көне турында комиссия әгъзаларына хәбәр итү.

3.5.3. Гаризаны комиссия тарафыннан карау

Комиссия үз утырышында гаиләнең учет эшен карый һәм гражданны ярдәмче программада катнашучы дип тану һәм торак сатып алуга субсидия алучы яисә гражданны ярдәмче программада катнашучы дип танудан баш тарту турында карар кабул итә.

Процедураның нәтиҗәсе: субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар.

3.5.4. Комиссия секретаре комиссия карарын беркетмә рәвешендә (бер нөсхә) рәсмиләштерә һәм имза кую өчен комиссия әгъзаларына тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: имзага тапшырылган бәяләмә.

3.5.5. Комиссия әгъзалары беркетмәгә имза сала һәм ул комиссия секретарена җибәрелә.

3.5.6. Комиссия секретаре комиссия беркетмәсен гаиләнең исәпкә алу эше белән бергә бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге регламентның 3.5.3 - 3.5.6 пунктчаларында билгеләнгән процедуралар комиссия утырышы көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия беркетмәсе һәм бүлек белгеченә җибәрелгән исәпкә алу эше.

3.6. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.6.1. Бүлек белгече әзерли:

субсидия бирү турында карар кабул ителгән очракта - планлаштырыла торган елда субсидия алырга теләк белдергән гражданнар исемлеге, гражданнарны категорияләр буенча бүлеп (алга таба - исемлек), һәм исемлекне Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгына (алга таба - министрлык) җибәрү турында өстәмә хат;

субсидия бирүдән баш тарткан очракта, баш тарту турында хат проектын Башкарма комитет җитәкчесенә имзага җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: субсидия алучыларның төзелгән исемлеген җибәрү турында теркәп җибәрелгән хат яисә Башкарма комитет җитәкчесенә имзага җибәрелгән баш тарту турында хат.

3.6.2. Башкарма комитет җитәкчесе теркәп җибәрелгән хатка яки баш тарту турындагы хатка кул куя һәм бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәп җибәрелгән хат яки бүлеккә җибәрелгән баш тарту турында хат.

3.6.3. Бүлек белгече кул куелган документны терки, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Субсидия бирү турында карар кабул ителгән очракта исемлекне теркәлгән хат белән министрлыкка җибәрә.

Субсидия кире кагылган очракта, имзаланган хат мөрәҗәгать итүчегә, комиссия карары кушымтасы белән, почта юлламасы белән җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрлыкка җибәрелгән исемлекне яисә хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хатны мөрәҗәгать итүчегә җибәрү.

3.7. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.7.1. Министрлык сертификатларның бланкларын алганнан соң 2 ай эчендә аларны ярдәмче программада катнашучы гражданнар исеменә рәсмиләштерә һәм күрсәтелгән гражданнарга бирү өчен сертификатларны җирле үзидарә органнарына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура министрлык регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тутырылган сертификатлар бланкларының Башкарма комитетка җибәрелүе.

3.7.2. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә сертификат килү турында хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура сертификат килгәннән соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә сертификат килү турында хәбәр итү.

3.7.3. Мөрәҗәгать итүче, бүлеккә килеп, кул куеп, сертификатны ала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче килгән вакыттан 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла. Сертификатны бирү чират тәртибендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган сертификат.

3.8. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.8.1. Гражданин муниципаль хезмәт алу өчен күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.8.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү билгеләнгән тәртиптә расланган КФҮ эше регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.3. Муниципаль хезмәт алуга КФҮдән документлар килгәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3 - 3.6 пунктлары нигезендә башкарыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклауны һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен тикшереп тору формалары түбәндәгеләр:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) билгеләнгән тәртиптә алып барыла торган эшләр башкаруны тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр план нигезендә (җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ярты еллык яки еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр дә карала ала, яисә мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча да.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп торуны гамәлгә ашыру максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы зат, шулай ук инфраструктура үсеше бүлеге белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар турындагы нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карамаган өчен җавап тота.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җавап бирә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (башкарыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылык тоталар.

